Краткая биография Героя Социалистического труда Стеллы Закиевны Габдрахмановой

Габдрахманова Стелла Закиевна родилась в Казани 17 ноября 1933 года. Отец Мухсинов Заки Мухамметзянович работал на руководящей должности в Татгосиздате. Мать Зайнап работала учительницей.

Довольно часто родителям приходилась задерживаться вечерами на работе, поэтому они вынуждены были отправлять девочку к бабушке, в деревню Кышклово (Кышлау) Атнинского района ТАССР.

Стелла пошла в первый класс сельской школы. С восьмого по десятый класс училась в Арской школе №1. Занималась наукой с большим интересом. Старательная, добросовестная Стелла после окончания 10-го класса поступила в руско-татарское отделение Казанского государственного педагогического института.

В 1955 году после окончания КГПИ, Стеллу направили работать в НовоКинерскую среднюю школу Кызыл-Юльского района. Это там, где недалеко прошло её детство. По направлению приехала в село Новый Кинер Арского района и стала работать учителем русского языка и литературы.

День за днем, накапливался опыт, а вместе с ним росло мастерство, крепла уверенность в правильности выбранного пути. Чтобы научить татарских детей любить русский язык и литературу, учитель творчески подходил к своему делу.

Дети искренне потянулись к своей молодой учительнице, им нравились её уроки, на которых установилась деловая, непринужденная атмосфера взаимного доверия. «Я стремлюсь, чтобы на уроках литературы школьники учились героизму, целеустремленности, выдержке у героев изучаемых произведений, серьезно задумывались над трагическими страницами «Отцов и детей», «Преступления и наказания», «Судьбы человека», - так пишет в статье о воспитании учащихся на уроках литературы С.З.Габдрахманова в журнале «Русский язык и литература».

Десятилетиями Стелла Закиевна вела просветительскую работу на селе, являлась участником Всесоюзного съезда учителей.

Щедро делилась она своим опытом с коллегами – более десяти лет возглавляла в районе методический совет преподавателей русского языка и литературы.

В этой школе она проработала более 30 лет. Высоко оценен ее труд. Только упорным, самоотверженным трудом можно добиться таких больших наград. В 1971 году С. Габдрахманова награждается орденом «Знак Почета». А летом 1978 года за большие заслуги в области обучения и воспитания подрастающего поколения присвоено звание Героя Социалистического Труда.

Более двадцати учеников пошли по стопам своего наставника. В настоящее время они работают учителями русского языка и литературы в школах по всей России. В октябре 2007 года на центральной площади города Арска установлен бюст Героя - С. З. Габдрахмановой. А с июня 2021 года Новокинерская школа носит ее имя.

Активно участвовала в общественной жизни. Постоянно читала лекции, знакомила тружеников села с новинками советской и зарубежной литературы, увлекательно рассказывала о великих классиках, участвовала в постановке спектаклей.

Сегодня Стелла Закиевна проживает в селе Новый Кинер. С супругом Хабиром Файзрахмановичом (муж Стеллы Закиевны Хабир Файзрахманович – тоже педагог, всю жизнь проработал учителем физики в Новокинерской СОШ) воспитали двух замечательных детей: Светлану и Айдара. Сын Габдрахманов Айдар Хабирович – инженер ООО «Мединструмент», дочь Гафиатулина Светлана Хабировна - врач-педиатр Арской ЦРБ.

## Социалистик хезмәт Герое Стелла Зәки кызы Габдрахманованың кыскача тормыш юлы

Габдрахманова Стелла Зәки кызы 1933 нче елның 17 нче ноябрендә Казан шәһәрендә туа. Әтисе Зәки Мөхсинов Татгосиздат оешмасында җитәкче вазифасында эшли, әнисе Зәйнәп - укытучы.

Эштән соң тоткарланып эшләүче гаилә кызлары Стелланы еш кына авылга әбисенә - ТАССРның Әтнә районы Кышлау авылына җибәрергә мәҗбүр булалар. Стелла беренче класска укырга да авыл мәктәбенә керә. 8-10 нчы классны Арчаның 1 нче номерлы мәктәбендә тәмамлый. Зур кызыксыну белән фәнгә тартыла. Тырыш, булдыклы булуы белән аерылып тора. Мәктәпне тәмамлаганнан соң Казан дәүләт педагогия институтының рус-татар бүлегенә укырга керә.

1955 елда, Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлагач, Стелланы Кызыл Юл районының Яңа Кенәр урта мәктәбенә эшкә җибәрәләр. Бу аның балачагы якында гына үткән җирдә булып чыга. Габдрахманова Стелла Арча районының Яңа Кенәр авылына килеп, рус теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли башлый.

Көннән-көн тәҗрибә туплана, аның белән бергә осталык үсә, сайлаган юлның дөреслегенә ышаныч арта. Татар балаларын рус телен һәм әдәбиятын яратырга өйрәтү өчен, укытучы үз эшенә иҗади якын килә. Балалар чын күңелдән үзләренең яшь укытучыларына тартылалар, аларга аның эшлекле, иркен рухлы дәресләре ошый, үзара ышаныч ике араны тагы да якынайта. «Мин рус әдәбияты дәресләрендә укучыларны батырлыкка, максатчанлыкка, өйрәтә торган әсәр геройларыннан сабырлыкка өйрәнүләренә, “Аталар һәм балалар”, “Җинаять һәм җәза”, "Кеше язмышы" әсәрләренең фаҗигале битләре турында җитди уйлануларына омтылам”, - дип яза ул “Русский язык и литература” журналында урнашкан мәкаләсендә.

Дистә еллар буе Стелла Зәкиевна авылда мәгърифәтчелек эше алып бара, Бөтенсоюз укытучылар съездында катнаша. Ул үзенең тәҗрибәсен хезмәттәшләре белән дә юмарт уртаклашты – ун елдан артык районда рус теле һәм әдәбияты укытучыларының методик советын җитәкләде. Яңа Кенәр урта мәктәбендә ул 30 елдан артык эшли. Аның хезмәте югары бәяләнә. Мондый зур бүләкләргә бары тик тырыш, фидакарь хезмәт белән генә ирешеп була. 1971 нче елда С.Габдрахманова «Почет Билгесе» ордены белән бүләкләнә. Ә 1978 нче елның җәендә үсеп килүче буынны укыту һәм тәрбияләү өлкәсендәге зур хезмәтләре өчен Социалистик Хезмәт Герое исеме һәм Ленин ордены бирелә.

Аның күп кенә шәкертләре остазлары эзләреннән киттеләр. Хәзерге вакытта алар бөтен Россия мәктәпләрендә рус теле һәм әдәбияты укытучылары булып эшлиләр. 2007 нче елның октябрендә Арча шәһәренең үзәк мәйданына Герой С.З.Габдрахманова бюсты куелды. Ә 2021 нче елның июненнән Яңа Кенәр мәктәбе аның исемен йөртә.

Стелла Зәкиевна җәмәгать тормышында актив катнаша. Даими лекцияләр укый, авыл хезмәтчәннәрен Яңа Совет һәм чит ил әдәбияты белән таныштыра, бөек классиклар турында мавыктыргыч итеп сөйли, спектакльләр куюда катнаши.

Бүгенге көндә Стелла Зәки кызы Яңа Кенәр авылында яши. Аның ире Хәбир Фәйзрахман улы да педагог, гомере буе Яңа Кенәр урта мәктәбендә физика укытучысы булып эшләде. Бүгенге көндә Хәбир Фәйзрахман улы инде вафат. Алар ике искиткеч бала - Светлана белән Айдарны лаеклы тәрбияләделәр. Улы Габдрахманов Айдар Хәбир улы - «Мединструмент» оешмасы инженеры, кызы Гафиятуллина Светлана Хәбир кызы - Арча үзәк район хастаханәсе табиб-педиатры.